Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

2021 елның 1 июне №28

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советының 2918 елның 24 сентябрендәге 89 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 7 пункты, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советының 2918 елның 24 сентябрендәге 89 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендәге 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 12 статьяда:

өченче абзацта» сүзләрен өстәргә, әлеге статьяның дүртенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш.»;

түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:
«Территорияне комплекслы үстерү турындагы карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.»;

дүртенче, бишенче һәм алтынчы абзацларны бишенче, алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга.

3) 13 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
- Осинники п., Яшьләр ур., 9А йорт (административ бина);

- Осинники п., Лесная ур., 2 йорт (Осинники мәдәният йорты),

шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районының Осинники
авыл җирлеге башлыгы, Кама Тамагы муниципаль
районының Осинники авыл җирлеге
Советы рәисе А.Х.Сәгъдиев